| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 гыйнвар г.Казань № 12

Лаеш муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Лаеш муниципаль районында урнашкан 1,1316 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеген 16:24:110301:577 кадастр номеры белән транспорт чараларына ягулык салу станциясен урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин